

Чаян

ISSN 0136-7110

САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * МАРТ * 2016 * КАЗАН

5

Валентин ДУБИНИН



АННАН-МОННАН
ИНФОРМ
СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

Американың "Б" планына җавап итеп, Рәсәй "Ы" операциясе булдырды.

Кино дөньясына иң зур йогынты ясаган кеше дип, Россия президентын таныдылар. Ди Каприоның Путинны уйныйсы килүен әйтүе була – аңа шундук "Оскар" премиясе тапшырыла.

Депутатлар тикшерүенә "юктан гына" налогын һәм "ни өчен икәнен әйтмичә үк" штраф проектын тәкъдим иттеләр.

Хөкүмәттә "Нефтькә бәя арту көтелә" проектын эшләү башланган.

Сәламәтлек саклау министрлыгында йөклелеккә узмау чарасының иң кулае ипотека дип кабул ителгән.

Политологлар сайлауларда Касьянов үзенең 2% ын алырга мөмкинлеген инкарь итмиләр.

Париж өстендә очучы НЛО безнең фанера булып чыккан.

"Яндекс-бөке"нең "Гугл-чокыр" дигән көндәше барлыкка килгән.

Ямьсез кызлар, Менделеевны үзләренә өмет чаткысы уяткан өчен изгеләр рәтенә кертүне таләп итәләр.

Безнең юлларны төннәрен бомбилләр бомбага тотуы ачыкланды.

Теге Тимур исемле кәҗә юлбарыс Байкалга үзенең командасын җыеп килгән.

Акылга сай кешеләр конкурсында беренче урынны конкурсның максатын аңлатып та аңламаган катнашучыга бирделәр.

ЖКХга бурычларын түләмәс өчен, бер гаилә үлгән булып кыланып яткан.

Допинг җәнҗалы. Безнең җиңелатлетикачылардан бернәрсә дә тапмаганнар.

Бер әби, сөйләшер кеше тапмыйаптырагач, полиция чакырткан.

Бер ир, башына шактый авыр нарат күркәсе төшкәч, наратны судка биргән.

Җыештыручыны, ачу белән идән юганы өчен, штрафка тартканнар.

Алексей БУЛАТОВ





ШОМБАЙ
болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Европада бюджет акчасын экономияләү максаты белән дәүләт чиновникларын велосипедта йөрергә мәҗбүр итәләр. Бәлки, безгә дә шулай итәргә кирәктер?

Р. БӘШИРОВА


АРЧА

– Бездә бу барып чыкмаячак, – диде Шомбай ага. **– Дүрт тәгәрмәчле, җылытыла торган күн утыргычлы, аудиосистемалы һәм шәхси йөртүчеле велосипед-вездеход кайда күргәнегез бар?**



Виталий ФЕОКТИСТОВ

Вячеслав БИБИШЕВ



Валерий АНТОНОВ

АДАШКАН ФИКЕРЛӘР

● Миндә бозык гаделлелек хисе: бездә бөтен нәрсәнең дә закон буенча булуын телим.

● Кризиска кадәр окладта гына утырды. Хәзер анысын да кистеләр.

● Яхшы күңелле кешеләр, усалларга караганда, күбрәк. Тик аларны тапканчы, үзең усалланып бетәсең.

● Яңа тормыш башлау планнарына көчле табигать килеп тыкшына: диванның тарту көче.

● Тук ачны аңламас, ач тукны күралмас.



Секретарь-референт булып кая җибәрсәләр, шунда эшли алам.

Бөтен юнәлешләрдә үсешкә әзермен.

Туризм өлкәсендә бер көн дә эшләгәнем юк, ләкин сәяхәт итәргә бик яратам.

Мәктәпне 2 нче разрядлы слесарь дәрәҗәсе белән тәмамладым.

Эш тәҗрибәсе: текстлар җыю, аларны принтердан чыгару, документларга печать кую.

Чайковский исемендәге консерваториянең саксофон классында биш ел кафель ябыштырдым.

Бөтен эш вакытымны эшкә багышлый алам.

Сезнең фирмагыз өчен бөтен нәрсәмне бирергә әзер.

(резюме)



СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

● Беркайчан да үзеңне башкалардан өстен куйма – яшен һәрвакыт иң биек агачны суга...

● Яхшы кунак янында хуҗа үзен өендәге кебек тоя.

● Булган ирләр өч-дүрт тапкыр өйләнә. Булдыксызлар шуның кадәр үк аерылыша.

● Сәламәтлекне сатып алып булмый... Аптекадагы бәяләр мөмкинлек бирми.

● Алар озак һәм бәхетле яшәделәр! Тик үзләре аңламады – бу ничек алай килеп чыкты соң?!.

Александр ЭЗЕКОВ

САТЛЫК ШӨҺРӘТ

Урраа! Ниһаять, туган илем мондый шөһрәт турында хыялланырга да кыймаган тыйнак героен танып алды. Мин, виртуаль продукция җитештерүче – өч кешедән торган чикләнгән җаваплылыклы җәмгыять җитәкчесе, «Ел предприятиесе-2015» Баш милли премиясенә лаек булганмын! Өстәвенә, «Россия җитештерүчесе» дигән Милли билге дә тапшырачаклар икән! Ләкин башта үзеннән-үзе сорау туды: «Минем хезмәт батырлыкларым турында Мәскәүдә ничек белгәннәр икән соң?»

«Дәүләт статистика мәгълүматларына таянып ясалган эшмәкәрлек эшчәнлегенең еллык рейтинг анализы нәтиҗәләре буенча, – дип белдерде миңа оргкомитет рәисе, Дәүләт Думасының өч чакырылыш экс-депутаты М. Е. Бугера, – сез җитәкләгән оешма регион буенча иң яхшыларның берсе дип табылды». Ә ахырда, гадәттәгечә, «сезнең фидакарь хезмәтегезгә зур соклану һәм ихтирам белән карыйбыз».

Премиянең Дәүләт Думасы депутатлары инициативасы буенча Эшмәкәрлек үсешенә булышлык фонды тарафыннан булдырылган икән. Ә фондның сайтында күп кенә дәрәҗәле кешеләрнең хуплау сүзләре басылган.

Моннан нәрсә килеп чыга соң? Мине Федераль ышанычлы тәэмин итүчеләр реестрына кертәчәкләр һәм исемемне фондның ел саен чыга торган икътисадый белдермәсендә басып чыгарачаклар. Кыскасы, «саргаеп беткәнче Мактау тактасында эленеп торачаксың». Хәзер минем тормышым салымнарны да гадәттәгедән вакытлырак түләргә мәҗбүр итәчәк. Шунда ук башыма кыю уй килде: «Бәлки, түләүләргә ташлама да ясарлар?»

Нурлы дан үрләренә менеп җитәр өчен соңгы адымны ясыйсы калды: оештыручыларга 94 мең сум күләмендә регистрация җыемы түлисе калды. Бу – бүләкләү церемониясендә шәхсән үзең катнашкан очракта. 40 мең сум – регалияләрне читтән торып кына алсаң. Зур ташлама белән бүләкләрнең өстәмә комплектын да алырга була, монысы бары тик 22 меңгә төшәчәк. Казанышларын бик югары түләүчеләр өчен 137 меңгә «вип-пакет» һәм «премиум» – 279 мең сум.

Акчасын кая куярга белмәгәннәр өчен менә шундый бормалы-сырмалы бүләкләр өләшү бизнесы. Һәм андыйлар табылып тора бит! Миндә искитмәле мактаулы исемнәр язылган дистәләгән визитка җыелды. Кемнәр генә юк анда: депутат наук, рыцарь ложи черно-белого креста, кавалер позолоченной лавровой ветки мира, действительный член Академии форматизации, Человек года Хогвардского университета... һәм җитди кыяфәт белән бүләкләү турында пресс-релизлар һәм сертификат күчермәләре җибәрәләр, ә номинантлар бөтен тиражы тәрәзә төбенә сыярлык журналларның тышларында басылган үз портретлары белән сокланалар...

Әллә үземә дә берәр нинди премия булдырып карарга микән? Район күләмендә булса да...

Әнвәр МАЛИКОВ

ЧАЯННАН. Берничә ел элек «Ил байлыгы» дигән мәкаләдә без Казанда бакча орлыклары белән сәүдә итүче фирманы ай саен диярлек «бүләкләп» торулары турында язган идек инде. Анда М. Е. Бугера фамилиясе искә алынган иде. Бүгенге материалда күрәбез – исән икән әле, каһәр суккыры! Масаерга яратучыларда бизнес ясау чәчәк ата! «Номинант»ларны саву дәвам итә!



Валентин ДУБИНИН



Алексей МАМАЕВ

ГҮЗӘЛ ЗАТЛАР

Валерий ТАРАСЕНКО



Хәнәфи БӘДИГЫЙ

ШАРТ

Безнең илдә бәйрәмнәр күп,
Атна саен диярлек.
Ахры, хәзер эшкә түгел,
Бәйрәмнәргә иярдек.

Ә шулай да бәйрәмнәрнең
Берсе безгә кадерле.
Бәлки, башкалары булмас,
Ул кадәр үк кадерле.

Яз җиткәнен хәбәр итеп,
Тамчы тама башлагач,
Кышкы калын киемнәрне
Өстән салып ташлагач,

Шунда бик нык көтеп алган
8 нче Март җитә;
Туңган хисләр ташуларга
Ияреп агып китә.

Алар Адәм, ягъни, безнең
Кабыргадан ясалган.
Ул – хатын-кыз бездән бөтен
Яхшы сыйфатны алган.

Үзләреннән дә өстәлгән
Бездә булмаганнары.
Безне кызыктырыр өчен
Арта барган аннары.

Шуңа алар матур, эшчән,
Күзләре тора көлеп.
Безнең арада яшиләр
Нәкъ хур кызлары кебек.

Алардагы аермалык
Безне нык ымсындыра.
Ымсындырып кына калмый,
Тәкатеңне сындыра.

Ир-атларны әсир итә,
Шундый – 8 нче Март!
Ләкин: "Әсир төшим!" – дисәң,
Алар шундук куя шарт!

Нияз БИШБАЛТА

ГҮЗӘЛ ЗАТЛАРГА...

Хатын-кыз бит һәрвакытта
Чибәр буласы килә,
Шуңа киткән акчаларны
Бер Ходай гына белә.
Модалы кием, дия бит,
Әйтерсең кигән капчык...
Үзе бик киң, изүләре
Кендеккә кадәр ачык.
Ирләр киемен кияләр
Гөнаһны онысалар,
Күпләрендә ботларына
Сыланып торган чалбар.
Мода диеп, ярымшәрә
Йөрүче кызлар да бар,
Күкрәк каплаучы тасмасы
Ычкыр бавыннан да тар.
Билдән түбән өлешләрен
Әйтеп тә торасы юк...
Алар өчен ояласың,
Борылып карагач ук.
Әдәп-әхлак тәртипләрен
Онытмасыннар иде,
Әзрәк ояла белсәләр
Күркәмрәк булыр иде...

Рәис ГАЙНЕТДИНОВ

СОҢАРДЫМ

Гыйшык утларында яныт-көеп,
Гаилә корып, туйлар үткәреп
Йөргән чакта уйламыйсың икән
Алда сине картлык көткәнен.

Картлык баса төшкәч, уйландыра,
Ләкин соңарыла икән шул.
Ике яклап таянып йөрергә
Ике хатын кирәк икән ул.

Людмила АЛАНЛЫ

"ҖИМЕШ", ДИЕП...

"Җимеш", диеп, миңа үрелмә син!
Өлгергән, дип, җете төсләре...
Синең өчен ачы булыр тәме,
Тамагыңа торыр төшләре!

"Алма", диеп, кулың сузма миңа –
"Дөп!" иттереп төшәм башыңа!
"Чәчәк", диеп, өзә күрмә берүк –
Чәнечкеләр калкыр каршыңда!..

Үрелмә син буең җитмәслеккә
(нәфес һәркемдә дә бар барын),
Синең кебек әрсез сырланнарга
Кырыс булыр минем җавабым!

Иван АНЧУКОВ



Алексей БУЛАТОВ



• • •

Телевизордан реклама роликлары бара: ир кеше микрофинанслау үзәгенә килеп, кредит ала. Экран астында эре хәрефләр белән текст пәйда була: Сак булыгыз! Бу трюк профессионал каскадер тарафыннан башкарыла, шуңа күрә аны кабатлау катгый тыела.

• • •

– Әйт әле, малай, синең кем буласың килә?
– Дивана.
– Ни өчен дивана?
– Чөнки барысы да: “Карагыз әле, теге дивана нинди шәп машинада йөри!” – дип шаккатып калалар.

• • •

– Ни белән шөгыльләнәсең?
– Күчемсез милек белән.
– Ничек итеп?
– Диванда ятам, селкенмим дә...

• • •

Эшкә алган вакытта:
– Сез эсперантоны кулланасызмы?
– Әлбәттә, – мин хәтта анда өч ел яшәдем дә!

• • •

Мединститутта имтихан:
– Авыру үзендә булмаган чирне эзли. Нинди диагноз куясыз?
– Ипохондрия!
– Ә бүтәннәрдә ул ничек дип атала?
– Түләүле медицина!

• • •

– Мин бүген тестирование буенча югары балл алдым.
– Шәп булган! Ә ул нинди тест иде соң?
– Канымда алкогольнең күпме микдарда булуын күрсәткән тест...

• • •


Укытучы Сәлимнән сорый:
– Сәлим, “Моя любимая передача” дигән темага иншаны үзең яздыңмы, әллә сиңа берәрсе булыштымы?
– Әйе, миңа әти булышты.
– Менә син әтиеңә әйт, тапшыруларны алу гына түгел, аларны карарга да була!..


• • •

Интернетка бик яхшы алмаш бар! Урамга чыгуың була – утыргычтагы әбиләр сиңа билге дә куя, кем икәнеңне дә сырлый, артыңнан дәрәҗәңне дә әйтеп кала...



Валерий ТАРАСЕНКО





Вячеслав БИБИШЕВ

Патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең тормышта шат күңелле, шаян һәм зирәк булганлыгы күпләргә мәгълүм. Хатыны Әминә ханым аның шундый икәнлеген еш кабатлап сөйли торган иде: ул рәхәтләнеп көлүләре дисеңме, шаярулары әйтәсеңме, тапкырлыгын, тәвәккәллеген... Дуслары белән җыелышып утыруларын, әдәбисәнгати бәхәсләр кабынып-кабынып алуларын... Шагыйрьнең мәзәккә ихласлыгы сугышка кадәр чыккан "Чаян" журналындагы шаян шигырьләреннән ташып тора.

Фронтта чакта дуслары аның: "Сугыш дәһшәтендә мин танк артыннан баруны хуп күрәм", – дип кабатларга яратуын исләренә төшерәләр. Ягъни, мәсәлән, окопта качып ятуны яки тылда калып җан асрауны түгел.

Шунысы да гаҗәп, аның иң шаян, төрткеле, үтә үткен сатира белән сугарылган, ләкин оптимистик шигырьләре фашист тоткынлыгында язылган. "Нинди күңел көрлеге, нинди егетлек һәм нинди какшамас ышанычлы көчкә ия булырга тиеш алар кебек үлемгә хөкем ителгән кешеләрдәге караңгы төрмә диварларын да яктыртырлык тормыш сөючәнлек!" – дип язган язучыбыз Гомәр Бәширов.

Гомеренең соңгы көннәренә хәтле Җәлил бу сыйфатын беркайчан да югалтмаган!

ТОМАУЛЫ ГЫЙШЫК

Егет чагым; үлеп гашыйк булдым
Контордагы бер яшь матурга;
Шагыйрьләрчә әйтсәк, гыйшкым минем
Чәчәк атты кышкы салкында.

Гөнаһ шомлык! Кышкы салкын белән
Томау төште беркөн борынга.
Һәм томаулы килеш киттем шулай
Кыз чакырган махсус урынга.

Утырабыз икәү, мин яулыкны
Калдырганмын онытып өемдә,
Ә борын нәкъ төпсез кое кебек,
Сәгать саен литр кимендә.

Нишлим инде, тәмам гаҗиз булдым,
Сүз әйтергә хәтта тилмерәм.
"Җаным!" дим дә "һач" дип төчкерәм,
"Сөям!" дим дә борын сеңгерәм.

Ансы бер хәл, бәлки төчкерми дә
Утырыр идем тавышсыз гына.
Гашыйкларча авыр сулыйм дисәм,
Ямьсез итеп борын сызгыра.

Бәла икән, дуслар, томау белән
Гыйшык арасында тартышу!
Кочакла да кызны, син әйт, имеш:
"Мин... һаптечу, сине... һаптечу!"

Утыра торгач, ахры, мин дәртләнеп,
Тотып кызның ике кулыннан,

Бер кызык сүз әйтеп көлгән идем,
Чыкты куйды куык борыннан.

Куык кунды барып кыз борнына,
Кыз аптырап битен каплады.
Мин дә сиздем шунда, мескен гыйшкым
Кызган куык төсле шартлады.

Кыз торды да кинәт, әйтте миңа,
Еламады үзе, көлмәде:
"Сөям, диеп кызга үрелгәнче,
Сөрт борныңны, егет, элгәре!"

Кызым китте, мин дә шул гарьлектән,
Түзәлмичә йөрәк януга,
Ни кызык бар миңа яшәүдән дип,
Аптекага киттем агуга.

Ярсый-ярсый бардым, һәм һич бушка
Булмады бу минем баруым.
Алып кайттым өйгә аптекадан
Бик куәтле... томау даруын.

Мин күрмәдем артык мәгъшукамны,
Томау бетте, гыйшкым онтылды.
Көчле булды дару, егет күңеле
Ике чирдән бергә котылды.

Яшьлек үтте, инде картаелды,
Яшим хәзер читтә, ышыкта.
Теләсәм дә, хәзер эләкми миңа
Бер томаулы гына гыйшык та.

ХӘДИЧӘ

Күрше кызы Хәдичә,
Шулай гадәттәгечә,
Озак йөреп бакчада,
Кичегеп кайтты кичә.

Каравылчы карт аның
Ишетмәгән кайтканын,
Шуңар күрә ачмаган
Хәдичәгә капканы.

Капкада тимер йозак,
Хәдичә көткән озак.
Тышта кунып булмый бит,
Булса да гәрчә йөз ак.

Ахры кызга уй керә,
Төнлә белән кем күрә?
Күп тикшерми Хәдичә,
Койма аша сикерә.

Кайтып керә йортына,
Кайткач бар да онтыла.
Тик кадакка эләгеп
Юбка гына ертыла.

Ул көн "соң" дип ямамый",
Аны-моны карамый.
Иртән китә хезмәткә,
Кичегергә ярамый.

Әле дә кичә соң кайтып,
Йоклаган кырын ятып.
Күрше карчык эшенә
Чак җибәргән уятып.

Менә бара ул, кара!
Юбка гына чайкала.
Исе китеп хатын-кыз
Юбкага карап кала.

Икенче көн ни күрәм? –
Бер елыйм да бер көләм.
Урам тулы хатын-кыз,
Бар да ерык юбкадан.

Күрче, күршем теккәнче,
"Мода" дип, көн үткәнче,
Бар да ерган юбкасын
Бот төбенә җиткәнче!

Әй, Хәдичә, Хәдичә!
Кичегеп кайтып кичә,
Нинди эшкә чуалдың?
Яңа мода чыгардың.

Кызлар, төнлә йөрмәгез,
Коймадан сикермәгез,
Тагын әллә ни ертып,
"Мода", дия, күрмәгез.



Олег ГОНОЗОВ

ГАИЛӘ НӘЗАКӘТЕ

Аня һәм Петя Рабиновичлар – әдәпле, тәрбияле, югары белемле кешеләр. Атна саен берәр нинди китап сатып алалар. Аня – астрология, Петя психология буенча. Телевидениедән бөтен яңалыкларны күзәтеп баралар, һәм аларны көнкүрештә файдаланалар.

Берзаман бер мэрның үзенең эшчеләренә “иртәгә килегез”, “мин белмим”, “бу минем мәсьәлә түгел” кебек сүзләр файдалануны тыюы турында хәбәр узды. Аня бу яңа шаукымны гаилә тормышына кертергә булды.

– Мэрның инициативасы турында ишеттеңме? – дип сорады ул.

– Ишеттем. Шуннан нәрсә?

– Мин гаиләбездә кайбер сүзләрне тыярга тәкъдим кертәм.

– Мәсәлән?

– Мәсәлән, синең яраткан “Өйрәтмә, яме!” дигән сүзеңне.

– Теләсәң ни эшлә.

– Менә бу “теләгәнеңне эшлә” сүзен дә тыярга вакыт. Син аны кирәк булса да, булмаса да көненә йөзләгән тапкыр әйтәсең.

– Син хаклы. Ә мин “кияргә бернәрсәм дә юк” һәм “бу күлмәк мине юанайта” сүзләрен тыярга тәкъдим итәм!

– Ярый. Син бүтән моны беркайчан да ишетмәссең. Ләкин мин дә моннан соң синең “Син бөтенесен дә әйттеңме?” дигәнеңне ишетергә теләмәс идем.

– Бик яхшы. Ләкин син дә “гырлама!” дип колагыма кычкырасы булма! Ишетәсеңме, беркайчан да!

– Әгәр дә син болай баклана башлагансың икән, мин дә синең “дөньяның бөтен акчасын алып бетереп булмас” һәм “эш качмас” дигәнеңне ишетергә теләмим! Аңладыңмы?

– Ә мин сиңа “җитте, бүтән салма”, “әнә, үзеңә көзгегә кара”, “яхшылап әйткәнне аңламасаң, әни янына кайтып китәм” дип әйтергә рөхсәт итмим!

– Сиңа әни янына китүем турындагы сүзләрем нәрсәсе белән ошамый?

– Ә сиңа “син бөтенесен дә әйттеңме?” диюем ник ошамый?

– Чөнки яз җитә, ә минем кияргә бернәрсәм дә юк, алырга кирәк...

Теләсәң ни эшлә...

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Артистлар – балалар кебек: аларга уйнарга гына булсын..

Их, үз хаталарында читтән торып кына өйрәнергә булса иде!

Әгәр дә аңа каршы барсаң, киләчәк тизрәк килә.

Шундый гадәти булмаган хаталар була: аларны тагын кабатлыйсы килә.

Үз намусы белән көрәштә җиңүче булып чыкты: аны сыртына салды.

Мәхәббәт канатларында начар һавада да очып күтәрелергә була.

Мәсьәләне шулкадәр еш күтәрделәр ки, ахыргы чиктә ул һавада асылынып калды.

Пычрак акча чиста кулга ябышмый.


Ни дисәң дә, юлдан язган, ул юлдан язган кызга караганда яхшырак.

Бердәм фикер битарафлар арасында гына була ала.

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды)




Сергей ТЮНИН



Ринат БӘШИРОВ



Виктор ФЁДОРОВ





КЫЙММӘТЛЕ ТӘҖРИБӘ

Һәркем булган белемен мөмкин кадәр табышлырак итеп файдаланырга тырыша. Менә Казанның бер сакчы системалар урнаштыру фирмасының директоры да тәҗрибәсенең юкка әрәм булуын теләмәгән. Эштән буш вакытында ул... урлау белән шөгыльләнгән. Сигнализациясе үзенә яхшы таныш булган кибет һәм офисларга кергән, әлбәттә. Шулай итеп ул 17 сакчы системасын өзеп, ике миллион сумнан артык акча үзләштергән. Аның белем дәрәҗәсенә бәяне суд бирәчәк.

ГЫЙБАДӘТ БӘЯСЕ

Түбән Новгородта гадәти булмаган процесс тәмамланды. Проект оешмасы җирле епархияне судка биргән. Компания заказ бирелгән котельный проектын вакытында башкарган, ләкин чиркәү бүлекчәсе тиешле сумманың яртысын гына түләгән. Судта дәгъвачы белән җавапчы килешенүгә киләләр: чиркәү тагын 200 мең сум түли, ә калган 250 меңне... гыйбәдәт укып кайтара. Гыйбадәт проект оешмасының башлыгы һәм аның гаиләсе сәламәтлегенә кылыначак. Кызганычка каршы, мондый әйберне дәүләт белән эшләү мөмкин түгел, югыйсә илнең бөеклеге өчен укынып, ипотека һәм ЖКХ бурычларын ярлыкарга булыр иде...

КАРА МУНЧА

Безнең мунчаның рәхәтен татырга Петербургка берьюлы утызлап африкалы килә. Юынган арада кара тәнле дуслар, телгә килеп, ызгыша башлыйлар. Ызгыш сугышуга күчә, себеркеләр, тазлар эшкә китә. Полиция килүгә кайнар канлы егетләрнең күпләре анадан тума килеш качарга өлгерә. Бу гадәти вакыйга шәһәрдә зур яңгыраш ала. «Коммунисты России» партиясе депутаты Сергей Малинкович Африка егетләрен хәтта илдән сөрүне таләп итә: «Без, совет кешеләре, ничә еллар буе кара тәнле халыкның азатлыгы өчен көрәштек, ә алар безгә нәрсә белән түли?! Мунчада исерек җәнҗал белән!» Депутат фикеренчә, дуамал африкалыларга Нельсон Мандела, Патрис Лумумба турында исләренә төшерергә кирәк, ә аннан соң «неоколониализмга каршы көрәшергә» өйләренә кайтарып җибәрергә кирәк.



Вожык

Соңгы вакытта Россия белән Белоруссия арасында мөнәсәбәтләр сизелерлек дәрәҗәдә җанланып китте. Менә «Чаян» да Минскидагы коллегаларыннан хат алды. «Без быел белорус укучыларын элекке Советлар Союзы территориясендә чыгып килүче юмористик басмалар белән таныштырырга булдык, – дип язалар «Вожык» хезмәткәрләре. – Шуңа күрә «Чаян» турында сөйләргә булдык». Бу бик яхшы нәрсә! Юмористик элемтәләрне җайга салырга вакыт...

«Вожык» үзенең исемендә ике билгеләмә йөртә: иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-сәнгати. Ул үзен тулы хокук белән сатира һәм юмор журналы дип тә атый ала. Тик һәрвакыт атамый. Болай да аңлашыла бит.

«Вожык» журналы дәһшәтле кырыгынчы елларда чыга башлады. Ә быел аңа нәкъ 75 яшь тула. Бу уңайдан юбилярга котлаулар баглыйбыз, аның хезмәткәрләренең һәм тугры авторларының һәрвакыт шундый яшь күңелле, җор һәм чәнечкеле булып калуын телибез.



Петр КОЗИЧ



Микола ГИРГЕЛЬ

Михась ЖУРОВИНА

ХАЛЫК МӘЗӘКЛӘРЕ

– Сезнең кызыгыз теге трамвай йөртүчегә кияүгә чыкмадымы әле?
– Юк, төпле карарга килә алмый әле.
– Сөйләшеп карагыз үзе белән, ул чакта егете дә кыюланып китәр!
– Ничек сөйләшим соң, трамвайда бит «Йөртүче белән сөйләшергә ярамый» дип язылган...

• • •

– Сезгә караган саен, алдымда ишәк күргән кебек булам.
– Моның булуы мөмкин түгел, мин көзге түгел ләбаса.

• • •

Суд залыннан судья чыгып килә һәм эчен тотып көлә. Икенче судья аннан сорый:
– Син нәрсә көләсең?
– Бик кызык мәзәк сөйләделәр.
– Сөйлә әле.
– Юк, син нәрсә, мин аның өчен алты ел бирдем.


Михась КОВАЛЕВ

ПРИОРИТЕТ ЮНӘЛЕШЛӘР БУЕНЧА БЕЛГЕЧ ГАРИЗАСЫ

«Төнге яктылык» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең кадрлар бүлеге мөдире Т. И. Павловскийга сату бүлеге мөдире, 1969 елгы, белорус, намуслы, хезмәт сөючән, тәртипле, перспектива күрә белүче һәм приоритет юнәлешләр сайлый белүче, югары белемле яхшы белгеч, начар гадәтләре булмаган үрнәккә куярлык гаилә башлыгы, ике менә дигән бала атасы Антон Демьян улы Сидоровтан гариза: исерек килеш урам чатында урам хәрәкәтен тәртипкә салып торганда мине эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре тоткарлау сәбәпле, характеристика бирүегезне үтенәм».



Петр КОЗИЧ



Валерий АНТОНОВ

ЯРТЫ СӘГАТЬ

– Бер сүз әйтмичә утырасың... Авызыңа су капкан кебек. Әһә, синең әйтер сүзең юкмы? Ичмасам, торып хатыныңа ярдәм итәр идең. Кибеткә йөрмисең, өйдән чүп тә чыгарганың юк, балкон рамасын рәтлим дигәнеңә инде ике ел була... Их, әни бит мине тезләнепләр үгетләгән иде: “Чыкма ул мөртәткә, үзеңне, булачак балаларыңны жәллә”, – дип. Җүләр идем шул, тыңламадым... Нигә улың турында бернәрсә дә сорамыйсың? Ул инде өченче тапкыр икенче сыйныфта укый. Ә синең бер генә тапкыр да ата-аналар җыелышында булганың юк. Минем әни анда гел йөреп торды, класс җитәкчесе полициягә мөрәҗәгать иткәнче. Хәзер дә ул аны мәктәпкә озата, укытучыларны эшкәртә, классташларын акылга өйрәтеп тора... Нәрсә авыр сулап куйган булдың, оятсыз күзләреңне яшергән буласың! Менә нәчәлстваңа барып җитәрмен әле, бөтенесен дә сөйләп бирермен. Бәлки, алар сине каплыйлардыр әле! Кайда утыра нәчәлстваң, әйт хәзер үк?

Күрешү тәмам! – дип җикерде почмакта торган сакчы. – Камерага шагом марш!..

Аннан соң чыгып киткән хатын артыннан күрешү бүлмәсенең ишеген япты, фуражкасын салып, маңгаеннан тирен сөртте:

– Карале, протоколсыз гына әйт әле миңа – ни пычагыма дип син ул убырлы карчык белән күрешү сорыйсың? Аны күргән саен тез буыннарым калтырый башлый...


– Ни пычагыма, дисеңме? – диде тоткын, елмаеп. – Аны күргән, тавышын ишеткән саен үземне ярты сәгатькә генә булса да өйгә кайтып килгән кебек тоям...

– Шуннан?

– Шуннан – өй ягына бүтән борылып та карыйсы килми...

Александр КАРШАКЕВИЧ рәсемнәре







Александр ЛЕВИТИН



Александр АЛЁШИН





Валерий ТАРАСЕНКО

Александр ЛЕВИТИН

МУЛЬТФИЛЬМ ТИРӘЛИ

Көне буе телевизордан катастрофа, үтерү күрсәтәләр. Ә «Ну погоди!» мультфильмын кичке унбердән соң гына карарга ярый. Анда бүре тәмәке тарта!

Улым урамнан кайтып керде һәм шунда ук бүлмәсенә – телевизор каршына, мультфильм карарга! Янына керәм, ә ул телевизор каршында кулларын күтәргән хәлдә басып тора.

– Улым, кулларыңа нәрсә булды?
– Ә (телевизордан аерылмыйча)?
– Кулларыңны ник күтәрдең?
– Ә-ә. Ул әни.
– Ничек инде, әни?
– Ул минем свитерны салдырды!

Өч яшьлек кызым Крокодил Гена турында мультфильм карап утыра. Пионерлар турындагы өлешен күрсәтәләр .

Мин, үземнең дәрәҗәмне күтәрергә теләп, әйтеп куям:


– Мин дә заманында пионер булдым, кызыл галстук бәйләп йөрдем, металлолом җыйдым...

– Баланың карашы җанланды, ул зур кызыксыну белән сорап куйды:

– Әни, ә синең Чебурашка булганың бармы?

Коррупция, җинаятьчелек, эшсезлек, фахишәлек чәчәк ата... Ләкин Россиядә мультфильмнар белән көрәшергә булдылар.

Виктор БОГОРАД



Виталий ФЕОКТИСТОВ





ЯХШЫЛЫКНЫҢ НАЧАРЛЫГЫ

Кадерле Чаян! Белгәнебезчә, беренче апрель – көтелмәгән гаҗәеп сюрпризларга бай көн. Менә без автойөртүчеләргә дә, бер ел элек шундый сюрприз ясадылар. Дөрес, бер дә көләсе килми торганны. Казан шәһәрендә түләүле парковкалар эшли башлаганга бер ел үтсә дә, шау-шуы һич кенә дә тынмый. Ничек тынсын, парковка өчен түләмәгән булсаң – ике мең ярым штраф! Ә бер сәгате – илле сум! Әлеге бәя башка шәһәрләрдән күпкә арзан булуы белән аерылып тора ул: шәһәрнең үзәгендә – утыз, ә Мәскәү шәһәрендә исә кичен һәм ял көннәре бөтенләй бушка. Шуңа күрә дә шәһәр вәкилләренең әйтүенә караганда, парковкаларның нибары 50% гына кулланыла. Ә бу бюджетка кергән акчаның икеләтә кимегәнен күрсәтә.

Шәһәр үзәген барлык транспорттан чистартырга кирәк дип саналган программа кире якка эшли башлады. Күзгә күренеп кибет, кафе, рестораннар бушап калды. Элек абруйлы саналган үзәктән эшмәкәрләр дә башка җайлырак җиргә күчә башладылар. Ник дисәң, анда ерткыч эвакуаторлар һәм туя белмәс паркоматлар юк...

А. ШАҺИЕВ

КАЗАН

МАТАШТЫРАЛАР...

Чаян дус! Мин – яшь, сәламәт, эшли торган кеше буларак, элек пенсионерларның ЖКХдан канәгать булмаганнарын һич аңламый идем. Ләкин кулыма гыйнвар ае өчен расчет китереп тоттыргач аңладым. Ике бүлмәле хрущевка өчен – 7 мең! Суны гына алыйк: кәгазьгә караганда, хатыным һәм кечкенә улым белән 10 куб бетергәнбез икән, ә счетчик 4 не генә күрсәтә.

Түбән Кама шәһәре җылылык өчен бәя күтәрелүне көтсә дә, гомумйорт ихтыяҗларына тотылган хезмәтләр өчен бәя күтәрелү турында сүз бармаган иде.

«Счетчик куегыз, үзегез тоткан кадәр генә түлисе, күпме акчагыз янга калыр!» – дип үгетләгәннәр иде безне үз вакытында. Дөрес, башта шулай булды. Ләкин коммуналка эшмәкәрләре үз табышларын югалта башлагач, гомумйорт ихтыяҗларына тотылган хезмәтләр өчен түләү керттеләр. Табыш керүнең түмен тоеп алгач, утка, суга, канализациягә дә түләтүнең тәмен тоя башладылар.

Тагын нәрсә уйлап табар икән әлеге коммуналь хәйләкәрлек?

А. АЛМАЕВ

ТҮБӘН КАМА

8 МАРТ һӘМ КЛАРА ЦЕТКИН

8 Март – Җир йөзендәге гүзәл затларга соклану һәм мәхәббәт көне. Язның бу бәйрәмендә без хатын-кызларга тирән ихтирамыбызны белдерәбез, аларның барлыгына шатланыбыз, бәхетләр телибез һәм чәчәкләр бүләк итәбез.

Халыкара хатын-кызлар көненең барлыкка килүе алман һәм Бөтендөнья эшчеләр хәрәкәте эшлеклесе Клара Цеткин исеме белән тыгыз бәйләнгән. Күпләр аның турында бик аз беләләр, бары тик сәяси көрәштән ары башканы белмәгән коммунистик хәрәкәт җитәкчеләренең берсе итеп кенә кабул итәләр.

Чынлыкта, Клара Цеткин бик кызык шәхес һәм үзенә тартып тора торган чибәр ханым була. Үсмер вакыттагы Эйснер фамилияле кыз укытучы белеме ала, ул чордагы беркадәр алдынгы карашлы яшьләр кебек, төрле сәяси түгәрәкләргә йөри. Менә шунда ул үзенең булачак ире Осип Цеткин белән таныша. Хөкүмәт даирәләре боларны ышанычсыз кешеләр исемлегенә кертеп, Алманиядән чит илгә сөрә. Шуннан соң яшь пар Парижга килеп төпләнә. Клара монда Максим һәм Константин исемле ике малай тудыра. Парижда алар революцион эшләрен дәвам итә.

1889 елда, ире үлгәч, Клара яңадан Алманиягә кайта һәм Роза Люксембург белән Алман социал-демократлар партиясенең сул канатына кушыла.

Шуннан соң Клараның тормышында кызыклы борылыш булып ала – ул Георг Цундел исемле яшь рәссамга гашыйк була. Өйләнешәләр. Георгның рәсемнәре бик яхшы сатыла. Алар хәтта йорт һәм машина сатып алу бәхетенә дә ирешәләр. Клара "Тигезлек" исемле газетаны редакцияләүдә эш йөртә. Клара Цеткин Алманиянең иң күренекле социалистына әверелә. Ул 1910 елда Копенгагенда Халыкара хатын-кызлар конференциясенең делегаты буларак катнаша.

Бу форумда Клара Цеткин елның бер вакытын – 8 Мартны хатын-кызлар проблемасына игътибарны юнәлтү көне итеп билгеләүне таләп итә.

1913 елдан әлеге таләп даими үтәлә башлый.

1914 елда Клараның ире белән мөнәсәбәте бозыла һәм алар аерылыша. Ул империалистик сугышка кискен каршы төшә, ә ире үз ирке белән фронтка китә. Сугыштан соң – 1933 елга кадәр Клара Рейхстаг депутаты буларак хезмәт итә, Советлар Союзына еш килә, ә Гитлер хакимияткә килгәч, СССРда кала.

Ә моңа хәтле Клара Цеткинның 22 яшьлек улы Константин 36 яшьлек Роза Люксембургның сөяркәсенә әйләнә. Шуның аркасында Роза белән Клараның дуслык мөнәсәбәтләре бозыла. Әмма яшь рәссам Кларны ташлаганнан соң, ә Константин Роза белән бозылышкач, сердәшләр яңадан дуслаша.

Соңгы тапкыр Клара Цеткин Рейхстагта 1932 елда утырышны алып баручы рәис сыйфатында катнаша һәм, бөтен чаралар кулланып, нацизмга каршы тору мәсьәләсен күтәреп, чыгыш ясый. Шуннан соң ул, протокол буенча, рәислекне сайлауларда күпчелек тавыш җыйган фракция вәкиле Герман Герингка тапшыра.

Клара Цеткин 1933 елның 20 июнендә Мәскәү янындагы Архангельскийда дөнья куя. Яндырылганнан соң, көле Кызыл Мәйдандагы Кремль стенасына урнаштырылган.

Интернет материалларына таянып,
Алмаз ХӘМЗИН әзерләде.



Леонид ЕЛЬКОВИЧ, «Чаян» № 13, 1962

Гадәт буенча...



Константин ВАСИЛЬЕВ, «Чаян» № 4, 1964

• • •

– Әни, ниһаять мин үземә кияү таптым!

– Ә кайчан таныштырасың?


– Әнә, аның «Мерседесы» килеп туктады. Хәзер ул машинадан чыга.

– Абау, ул синнән егерме яшькә олырак түгелме соң?

– Бу ул түгел, әни, монысы аның төпчек малае.



Валентин ДУБИНИН



Вячеслав ШИЛОВ

РӘХМӘТ СИҢА

(Ш. Маннаповка ияреп)

Рәхмәт сиңа, матур итеп көлгән өчен,
Уйларымны күзләремнән күргән өчен.
Атна саен күлмәк-ыштаннарым юып,
Хәтта носки размерымны белгән өчен.

Рәхмәт сиңа, мине эштән көткән өчен,
Алып кайткан хезмәт хакым җиткән өчен.
"Салып" кайтсам, бер карашың белән
Өч секундта мине аек иткән өчен.

Рәхмәт сиңа безнең алтын көзләр өчен,
Кыз-улларым сиңа карап үскән өчен.
Сабырлыкта күрелмәгән рекорд куеп,
Минем холык-фигылемә түзгән өчен...

Ринат АБЗАЛОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

Валентин ДРУЖИНИН





ЧуАр пресса

КҮБЕКЛЕ ДРАМА

Англиянең Вустер шәһәрендә яшәүче бер хатын яңа гына юган джинсы чалбарының кесәсендә онытылып калган лотерея билеты таба. Аның сөйләп бетергесез шатлыгына, билет отышлы була. Сумма күп тә түгел, әз дә түгел – 47 миллион доллар. Тик шатлык озакка бармаган. Кер юу машинасында бәхетле билетның серия номеры һәм штрих кодына зыян килгән.

ӘТИ САЛЮТЫ

Омскида яшәүче берәүнең малае туу турындагы хәбәр бик шатландырган, һәм бәхетле әти роддом каршында фейерверк аткан. Салютның өч петардасы ачык тәрәзәдән кереп, ординаторскийда шартлап тәмамланган. Бәхеткә каршы, берәү дә зыян күрмәгән, тик "салют атучы" атага штраф барыбер түләтәчәкләр.

СЕЛФИ КОРБАНЫ

Калифорниядәге бер фатирга карак кергән. Беренче эш итеп ул смартфонын зарядкага куйган. Аннары акча һәм алтыннар эзләргә керешкән. Җинаять урынына полиция килгәч, онытылып калган гаджетны тапкан. Җинаятьчене селфилары буенча эзләп табу авыр булмаган.

ЧИЗБУРГЕРГА КИЯҮГӘ

Англияле Сэм Смит үзенең исемен бөтен дөньяга танытырга хыялланган. Бервакыт "Бургер Кинг" кафесында утырганда, аңа исемен һәм фамилиясен үзгәртергә дигән уй килә. Хәзер ул – Икеле Чизбургер Бекон белән. Бу хәбәр тиз арада Интернетта тарала. Тик аның йөргән кызы уйга баткан – Чизбургерга кияүгә чыгарга микән, юк микән?





Генрих БЮТНЕР (Германия)



КОВЕРТИ (США)



ТАВЕС (Бразилия)



УНГЕР (Бөекбритания)



Удо ЛАРСЕН (Швеция)



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

– Кадерлем, үп әле мине!

– Шаштың мәллә, нинди инде ул унынчы ел бергә яшәп туйганда үбешү?!

• • •

Хатыны иренең яшереп куйган акчасын тапкан.

– Бу кадәрле акча каян килгән?

– Менә сиңа бүләк алыр өчен җыйдым...

– Шулаймыни? Нигә соң ул бик аз?

• • •

– Менә син нәрсәне сайлап алыр идең – слесарьнең матур кызы булуны, әллә миллиардерның ямьсезенме?

– Син әле аңламыйсың – миллиардерларның ямьсез кызлары булмый...

• • •

– Нигә аерылышырга булдыгыз? Сез бит хатыныгыз белән 20 ел бергә торгансыз!

– Мәрхәмәтле хөкемдар, сез мине әле бик аз җәфа чиккән дип уйлыйсызмы?

• • •

– Балаларың сиңа нинди мөнәсәбәттә?

– Аллага табынган кебек.

– Ул ничек була инде?

– Алар мине тыңламыйлар да, киңәшләремне дә үтәмиләр. Кайвакытта мине күрмәмешкә дә салыналар. Әгәр дә инде үзләренә бирәр нәрсә кирәк булса – шундук мине чакыралар...

• • •

– Бензин күпмегә кыйбатлана?

– Нефтьнең бәясе күпмегә төшә? Шуннан чутлап чыгар инде...

• • •

– Нишлисең?

– Немецча өйрәнәм.

– Нигә?

– Алманиягә ычкынырга исәп.

– Гарәпчә өйрәнсәң әйбәтрәк булыр!

– Мин сиңа Алманиягә китәсем килә дип әйттем бит инде!

– Мин дә сиңа шуны туглыйм ич. Гарәпчә өйрән!

ЧАЯН
(СКОРПИОН)
САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ
№ 1 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам: **Александр АЛЁШИН**
Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2
Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.

татмедиа
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
16+
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Лиана МӘРДАНОВА

КЫЧКЫРЫП ӘЙТӘСЕ ИДЕ...

Мин әйтәм, түрәләр яхшы эшли бездә. Ял итүне дә белмиләр – төнлә хоккей уйныйлар. Кичә шуларны карарга барган идем: трибунадагы урындыкларны күрсәң, малааай! Падишаһларныкы кебек инде менә: утыргач, тегеләрнең боз буйлап шуып йөргәненә карап, йоклыйсы гына килеп тора. Әле кичә, Гали абзый белән дә сөйләшеп утырган идек: "Хоккейны нык яраталар өстәгеләр. Рәхмәт!" – ди.

Гали абзый безнең күршедә генә тора. "Во" мужик! Әле, әнә, бүген дә телевизордан хоккей карый. Ул хоккей караганда мин тыңлап кына утырам, беренчедән, комментаторлардан яхшырак аңлата: кирәк вакытта сүгенә, кирәгендә карчыгына кычкырып ала. Икенчедән, стеналар "так себе" бездә, күршеләрнең ашаганы да ишетелә... Мин аның хәтта ничек утырганын да беләм: залның уртасына 90 нчы елларда алынган креслоны кучереп, каршына аяк куярга табурет куеп, Гали абый хоккейга чума:

– Кит әле, карчык, кит әле! Йөрмә экран каплап! Ну, ну! Йөгер инде, шуа белмәсәң! Кая бәрәсең? Кая бәрәсең? Кәшәкә ул сиңа боерык яза торган каләм түгел!..

Гали абзый хоккейны гел шулай дөньясын онытып, шашып карый. Галимә апаның каршына китереп куйган ашның яртысын эчеп, тәлинкәсен идәнгә тәгәрәткәнен сизми дә кала.

– Гали, дим. Кычкырма ул чаклы. Җиңәрләр әле! Син менә монда кычкырып утырмасаң җиңмәсләр шул, ы-ы! – Галимә апа гадәттәгечә тузан сөртәдер инде.

– Җиңәләр, сиңа әнә, җиңәләр! Кәшәкәгә таянып, арт саннарын селкетеп йөргәннәр, ди, дә, җиңгәннәр, ди! Нервычат иттереп син торасың тагын! Гооол!!! Хатын, гооол! – дип кычкырды да Гали абый, креслога басып, хәләленең кочагына ташланды. Бер центнерлы гәүдәнең инде алтмыш килога калганы үзенә кунаклаячагын көтмәгән карчык идәнгә гөрселдәп килеп төште. Хоккей өчен соңгы ыштанын гына түгел, трусигын да сатарга әзер булган Галиенең чиратгагы шатлыгын уртаклашу ысулы иде бу.

Гали абыйның яман шеш белән авырганына инде ике ел тулып килә. Табиблар якын арада операция ясамасак, тагын өч айдан үлеп китәргә мөмкин дип мыгырдады. Уллары министрларга да, җырчыларга да, җырлаучыларга да, бизнесменнарга да барып карады инде, берсенең дә бер тиен акчасы юк.

Идәндә әүмәкләшеп "ух-пух" килеп яткан җиреннән Галимә апа:

– Алла, җаным! Шушы бер хоккеистың өчен көненә миллион ат алырлык акча түлиләр! Синең кебекләрне атнасына ике коткарып булыр иде, ачуым бер килмәгәе! Унбер әзмәвердәй егетнең кара тизәкне боз буйлап шудыртуына карап гомерең үтә бит инде, карт алаша!

– Борчылма, карчык, азрак түз инде. Мишайтламый башлармын! Ике-өч атнадан "мик" итсәм, тузаныңны сөртеп, ашарыңа пешерергә беркем комачауламас!

Радикулитын шыгырдатып, хәләленә акыл кертергә маташкан Галимәттәй кухняга чыгып китте булса кирәк. Тавышы якынайды.

– Гомер акыл кермәс моңа! Гомер! Шуларны карап чиргә сабышып беттең! Син беләсеңме аларның берсенә генә дә ун ат алырлык акча түлиләр! Син ят шушында үлемеңне көтеп!

Күрше кухняда барган бу монологны Рәсәйнең иң югары ноктасыннан кычкырып әйтәсе иде дә, әйткәнеңне аңласалар, бәхетеңнән егылып үләсе иде. "Эх! Аңламый шул халык! Хоккей кебек чуртмуртның илдәге сәясәтнең мөшкел хәлен каплап торучы бер ашъяулык икәнен күрмиләр бит..." – дип көрсенде Галимәттәй һәм елап җибәрде...




Виктор ФЁДОРОВ

Уйна да, уйла да!

ЧАЯНВОРД

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.





1. Матрешка белән аракының охшашлыгы?

2. Ни өчен Максим Галкинны хәрби хезмәткә алмыйлар?

3. Ничек итеп яхшырак сәяхәт кылып була?

4. Ямансу һәм ялгызлыктан интегәсезме? Берәү дә шалтыратмый, язмыйлар да, килмидәме? Хыялланмыйсыз, могҗизаларга да күмелмисезме? Бу халәттән ничек чыгарга?

5. Рәсәйнең җыелма командасына нинди тренер кирәк?

6. Сәламәт туклану чарасының төп сере нәрсәдә?

ҖАВАПЛАР

1. Беренчесен ачканнан соң икенчесен, өченчесен ачарга кирәк... 2. Чөнки аның җилкәсенә әбине карау, тәрбияләү йөкләнгән. 3. Яңа илендә сине исләрендә калдырырлык һәм туган илендә онытмаслык итеп йөреп. Шул ук вакытта бу илләрдә үзеңне эзләп тә интекмәсеннәр иде. 4. Кредит алыгыз да түләмәгез! 5. Сталин кебек. Алтын отмыйсыз икән, аны үзегезгә, җиде кат тирегез чыкканчы һәм күпмедер гомерегезне сарыф итеп, казып, юып алырга туры киләчәк. 7. Ашамлыклы капның тышына язылган аңлатмасын укымаска.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемнәрен укыгыз. Журналыбызның 3 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **«ХАТЛАР ЯЗАМ»**, **«ШАХТА»**.


Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Ә. ГАРИПОВА (Әлки р-ны, Иске Салман ав.),
Р. ЙОСЫПОВ (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
Р. ИШМОРАТОВ (Арча р-ны, Урта Сәрдә ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
Д. НУРГАТИНА (Алексеевский р-ны, Урманасты Шонталасы ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Норма авылыннан **Мәгъфүрә МИҢНЕМУЛЛИНА!**



Альберт ДЮБУА (Франция)



Француз карикатурачысы Альберт ДЮБУА XX гасырда яшәгән һәм иҗат иткән. Ул хайваннарны бик яраткан һәм шуңа күрә аның иҗатының төп темалары коррида һәм март мәчеләре булган. Тореадорлардан көлеп, бу тамашаны кабул итмәвен күрсәткән. Франциянең көньягында һәм Каталониядә корриданың тыелуына Дюбуаның иҗаты да тәэсир иткәндер, мөгаен.

